ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында

# Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында

# Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында

КАЗАН
2017

һәм вазыйфаи затлар Федераль законның 28 статьясындагы 1 өлешендә каралган мәгълүматны гражданнар файдалана алырлык урыннарда, массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга йә гражданнарга бүтән ысул белән җиткерергә тиеш.

2. Җирле үзидарә органнары хокукый мәгълүматны халыкка җиткерүне һәм аны хокукый гыйлемле итүне муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыра ала.

3. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү югары белем бирү мәгариф оешмаларының юридик клиникалары һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

*(2014 елның 28 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

18 статья. **Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле гамәлләрне финанслау**

1. Федераль законнар, әлеге Закон һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырылуы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм алар ведомствосындагы учреждениеләргә йөкләнә торган түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле гамәлләрне финанслау Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән башкарыла. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгымнарны бүтән субъектлар акчалары исәбеннән финанслау тиешле субъектлар тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда каралган очракларда гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларның хезмәте өчен түләүгә, аларның мондый ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасының чыгымнар йөкләмәсе булып тора.

3. Җирле үзидарә органнарының гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукына өстәмә гарантияләр билгеләүгә бәйле чыгымнарын финанслау җирле бюджетларның чыгымнар йөкләмәсе булып тора.

19 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 2 ноябре
№ 73-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

*(2011 елның 10 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы, 2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

Әлеге Закон «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты нигезендә «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

1 статья. **«Хезмәт ветераны» исеме бирелә торган затлар**

1. «Хезмәт ветераны» исеме түбәндәгеләргә бирелә:

1) СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән, йә СССРның яисә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәренә лаек булган, йә Россия Федерациясе Президентының мактау грамоталары белән бүләкләнгән яисә Россия Федерациясе Президенты рәхмәтенә лаек булган, йә эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән һәм пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булган затларга;

2) хезмәт эшчәнлеген Бөек Ватан сугышы чорында балигъ булмаган яшьтә башлаган һәм ирләр өчен кимендә 40 ел һәм хатын-кызлар өчен кимендә 35 ел хезмәт (иминият) стажы булган затларга.

2. Әлеге Законда «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары дигәндә, федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство бүләкләре дип аңларга кирәк.

*(статья 2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2 статья. **«Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен кирәкле документлар**

1. «Хезмәт ветераны» исемен бирүне дәгъвалаучы затлар даими яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органына түбәндәге документларны тапшыралар:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан расланган рәвеш буенча «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында гариза;

2) граждан паспортының яисә аның шәхесен раслый торган башка документының күчермәсе;

3) 3 x 4 см үлчәмле фотография;

4) әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән документларның күчермәсе.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән затлар түбәндәгеләрне раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар:

1) СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнүне, йә СССРның яисә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре бирелүне, йә Россия Федерациясе Президентының мактау грамоталары белән бүләкләнүне яисә Россия Федерациясе Президентының рәхмәт белдерүен, йә «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнүне;

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2) пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булуны.

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән затлар түбәндәгеләрне раслый торган документларның күчермәләрен тапшыралар:

1) 1941 елның 22 июненнән башлап 1945 елның 9 маена кадәрге чорда балигъ булмаган яшьтә хезмәт эшчәнлеге башлануын;

2) хезмәт (иминият) стажы ирләр өчен кимендә 40 ел һәм хатын-кызлар өчен кимендә 35 ел булуны.

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Бөек Ватан сугышы елларында балигъ булмаган яшьтә хезмәт эшчәнлеге башлануын раслый торган документлар: хезмәт кенәгәләре, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнары яисә вәкаләтле органнар тарафыннан архив мәгълүматлары нигезендә бирелгән белешмәләр.



Комиссия Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм дәүләт идарәсен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында бердәй финанс, бюджет, салым һәм валюта сәясәтен үткәрүне тәэмин итүче органы, Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы һәм бүтән дәүләт органнары һәм оешмалар вәкилләреннән тора.

Вәкаләтле орган җитәкчесе комиссиягә җитәкчелек итә.

3. Комиссия турындагы нигезләмә вәкаләтле орган җитәкчесенең карары белән раслана.

4. Сәламәтлегенә, туганнарының (якыннарының) гомеренә һәм сәламәтлегенә зарар китерүгә йә аның мөлкәтенә зыян салуга, туганнарының (якыннарының) мөлкәтенә зыян салуга бәйле рәвештә авыр тормыш хәлендә, шулай ук кичектергесез гамәлләрне таләп итә торган бүтән хәлләрдә калган һәм түләүсез юридик ярдәмгә мохтаҗ гражданның ашыгыч очракта Татарстан Республикасы дәүләт органнарына мөрәҗәгате буенча гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы йә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тарту хакындагы карар мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә комиссия тарафыннан кабул ителә.

5. Комиссиянең түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тарту турындагы карарына карата граждан суд тәртибендә шикаять белдерергә мөмкин.

16 статья. **Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар**

1. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасы ихтыярый башлангычларда корыла.

2. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар юридик клиникалардан (студентларның консультацияләр бюроларыннан, студентларның юридик бюроларыннан һәм башкалардан) һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләреннән гыйбарәт.

3. Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасындагы аерым катнашучыларның оешу тәртибе, вәкаләтләре һәм статусы Федераль закон белән җайга салына.

17 статья. **Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү**

1. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, җирле үзидарә органнары

2. Әгәр граждан Федераль законда һәм әлеге Законда каралмаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында сораса, гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тартыла.

3. Законнар нигезендә түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган һәм, түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап, дәүләт органнарына яисә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатка мөрәҗәгать иткән гражданга түбәндәге очракларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтелми һәм гариза теркәлгән көннән биш эш көне эчендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең мөмкин булмавы турында бәяләмә бирелә, әгәр граждан:

1) хокукый характерда булмаган мәсьәлә буенча түләүсез юридик ярдәм сорап мөрәҗәгать итсә;

2) тиешле таләпләр кую өчен хокукый нигезләр булмаган килеш, гариза, шикаять, үтенечнамә яисә хокукый характердагы башка документ төзеп бирүне һәм (яисә) судта, дәүләт яисә муниципаль органда, оешмада үз мәнфәгатьләрен чагылдыруны сорап мөрәҗәгать итсә;

3) судка, дәүләт яисә муниципаль органга, оешмага мөрәҗәгать итүгә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән каршылыклар булган килеш, судка гариза язуны һәм (яисә) судта, дәүләт яисә муниципаль органда, оешмада үз мәнфәгатьләрен чагылдыруны сорап мөрәҗәгать итсә.

4. Вәкаләтле дәүләт органнары һәм дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар, әгәр прокурор, шушы гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап, федераль закон нигезендә судка гариза белән мөрәҗәгать иткән булса, гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтмиләр.

5. Гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

6. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә җибәрелә торган акчаларны тотуны тикшереп тору бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 15 статья. **Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы карарларны кабул итү тәртибе**

1. Әлеге Закон максатларында ашыгыч очракларга табигый бәла-казалар (гарасатлар, янгыннар, су басулар, корылык, боз сугу), эпидемияләр, массакүләм чуалышлар, погромнар, ут төртеп яндырулар, афәтләр, шул исәптән һәлакәтләр, гадәттән тыш һәм хәрби хәл кертү, кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган башка охшаш очраклар кертелә.

2. Вәкаләтле орган авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) төзи.



5. Әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән документларның күчермәләре белән бергә аларның төп нөсхәләре дә тапшырыла, документлар кабул ителгәндә алар күчермәләре белән чагыштырып карала һәм мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

6. «Хезмәт ветераны» исемен бирүне дәгъвалаучы заттан, әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә каралганнардан тыш, башка документлар таләп итү тыела.

### 3 статья. **«Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен кирәкле документларны территориаль социаль яклау органнары тарафыннан карау тәртибе**

1. Мөрәҗәгать итүченең даими яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органы «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында гариза, әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән документлар белән бергә, кергән көннән башлап биш эш көне дәвамында түбәндәгеләрне башкара:

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1) «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен кирәкле документлар тапшырылган документларны тикшерә;

2) кабул ителгән документларны «Хезмәт ветераны» исемен бирүне дәгъвалаучы затларны исәпкә алу ведомостена терки, аның рәвеше Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органына «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында хат-үтенечнамә, бу исемне дәгъвалаучы затларны исәпкә алу ведомостеның территориаль социаль яклау органы җитәкчесе тарафыннан расланган күчермәсе белән бергә, җибәрә;

4) документларны кабул итүне кире кага.

2. «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен документлар кабул итүне кире кагу сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2 пунктларында санап кителгән нигезләрне раслый торган документларның булмавы;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне бозып тутырылган документлар тапшыру;

3) тапшырылган документларның дөрес булмавы.

3. Документларны кабул итүне кире кагу турындагы хәбәрнамә тиешле карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, территориаль социаль яклау органы тарафыннан мөрәҗәгать итүченең даими яшәү урыны буенча җибәрелә.

4. Территориаль социаль яклау органының «Хезмәт ветераны» исемен бирүне дәгъвалаучы затның документларын кабул итүне кире кагу

турындагы карарына карата Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органына йә судка шикаять бирелергә мөмкин.

4 статья. **«Хезмәт ветераны» исемен бирү**

1. «Хезмәт ветераны» исеме Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан бирелә.

2. «Хезмәт ветераны» исемен бирү турындагы карарны территориаль социаль яклау органы тарафыннан «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында хат-үтенечнамә, бу исемне дәгъвалаучы затларны исәпкә алу ведомостеның күчермәсе белән бергә, тапшырылган көннән алып 14 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы кабул итә.

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы «Хезмәт ветераны» исеме бирелгән гражданнар реестрын алып бара.

4. «Хезмәт ветераны» исеме бирелгән гражданнар реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **«Хезмәт ветераны» исеме бирелгән затларга таныклыклар бирү тәртибе**

1. «Хезмәт ветераны» исемен бирү турындагы карар нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы биш эш көне дәвамында бердәй үрнәктәге «Хезмәт ветераны» таныклыгын тутыра.

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. «Хезмәт ветераны» исеме бирелгән затка таныклык аның даими яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органы тарафыннан бирелә.

3. «Хезмәт ветераны» таныклыгын бирү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6 статья. **«Хезмәт ветераны» таныклыгы дубликатын бирү тәртибе**

1. Таныклыкның дубликаты «Хезмәт ветераны» таныклыгын югалткан (бозган) очракта ветеранның таныклыкны югалту (бозу) шартлары күрсәтелгән гаризасы нигезендә, шулай ук паспортының күчермәсе һәм 3 х 4 см үлчәмле фотографиясе булганда тутырыла һәм бирелә.



2) паспорт яисә гражданның шәхесен таныклый торган башка документ;

3) түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар категорияләренең берәрсенә кертелүне раслый торган документ;

4) әлеге Законның 12 статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда гражданнарның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы таләпләрен нигезли торган документлар.

2. *Үз көчен югалтты.*

*(2016 елның 12 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Әлеге статьяда каралган документлар, әгәр гражданның түләүсез юридик ярдәм алырга шәхсән үзе мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булмаса, түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия граждан үтенече буенча башка зат тарафыннан да тапшырылырга мөмкин. Бу очракта гражданның вәкиле, әлеге статьяда күрсәтелгән документлардан тыш, шәхесен раслый торган документ, ышанычнамә яисә законлы вәкил хокукын раслый торган документ тапшыра.

4. Түбәндәге очракларда документларны кабул итүдән баш тартыла:

1) түләүсез юридик ярдәм турында гариза белән тиешсез зат мөрәҗәгать иткән булса;

2) әлеге статьяның 1 өлешендә каралган барлык документлар да тапшырылмаган булса.

5. Документларны кабул итүдән баш тартуга карата вәкаләтле органга яисә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

14 статья. **Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Әлеге Законның 12 статьясындагы 2 өлешендә каралган очракларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм түбәндәге ярдәмне сорап мөрәҗәгать иткән гражданга күрсәтелә:

1) хокукый характердагы мәсьәлә буенча;

2) бер үк яклар арасындагы бәхәс буенча, бер үк әйбер турында һәм бер үк нигезләр буенча кабул ителеп закон көченә кергән суд карары белән элек хәл ителмәгән мәсьәлә буенча:

а) суд карары (хөкеме) белән;

б) дәгъва белдерүченең дәгъваны кире кагу белән килешүенә бәйле рәвештә эш алып баруны туктату турындагы суд билгеләмәсе белән;

в) җәмәгать килешүен раслауга бәйле рәвештә эш алып баруны туктату турындагы суд билгеләмәсе белән;

3) арадашчы судның бер үк яклар арасындагы бәхәс буенча, бер үк әйбер турында һәм бер үк нигезләр буенча яклар өчен мәҗбүри үтәлергә тиешле кабул ителгән карары булмаган мәсьәлә буенча, арадашчы суд карарын мәҗбүри үтәүгә карата башкару кәгазен бирүдән суд баш тарткан очраклардан тыш.

б) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә яисә гадәттән тыш хәл аркасында вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

*(2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

в) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

г) инвалид балаларга, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга дәүләт ярдәме чараларын тәэмин итү;

*(2 пункт 2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) үзләрен хокукка сәләтсез дип тану турында гариза судта карала торган гражданнар булсалар;

4) сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнар булсалар – реабилитацияләүгә бәйле мәсьәләләр буенча;

5) психиатрия стационарына мәҗбүри салу турында яисә психиатрия стационарында мәҗбүри яткыру срогын озайту турындагы эшләре судларда карала торган гражданнар булсалар;

6) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнар булсалар – гадәттән тыш хәл аркасында бозылган мөлкәти хокукларын, мөлкәти булмаган шәхси хокукларын торгызуга, гадәттән тыш хәл аркасында килгән зыянны түләүгә бәйле мәсьәләләр буенча.

*(6 пункт 2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

4. Гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнарның дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыру тәртибе, шартлары һәм аны оештыру-хокукый тәэмин итү Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән җайга салына.

*(4 өлеш 2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

13 статья. **Татарстан Республикасында гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алуы өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тапшыру тәртибе**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу өчен гражданнар түбәндәге документларны тапшыралар:

1) кирәкле түләүсез юридик ярдәм төре һәм аны күрсәтү нигезе күрсәтелгән килеш, вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган рәвеш буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында гариза;



2. Гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итү мөрәҗәгать итүченең даими яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Ветеран таныклыгының дубликатын тутыруны территориаль социаль яклау органы тарафыннан кирәкле документлар тапшырылган көннән алып биш эш көне дәвамында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы башкара.

*(2016 елның 9 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

7 статья. **Күчеш нигезләмәләре**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә хезмәт ветераннарына бирелә торган социаль ярдәм чараларын алучы һәм әлеге Закон үз көченә кергән көнгә «Хезмәт ветераны» таныклыгы булмаган затлар тиешле үрнәктәге таныклыкны алу өчен даими яшәү урыны буенча территориаль социаль яклау органына түбәндәгеләрне тапшыралар:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан расланган рәвеш буенча гариза;

2) граждан паспортының яисә аның шәхесен раслый торган башка документының күчермәсе;

3) 3 x 4 см үлчәмле фотография;

4) территориаль социаль яклау органы тарафыннан бирелгән социаль ярдәм чараларын алу хокукы турында белешмә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергәнче бирелгән «Хезмәт ветераны» таныклыклары үз көчләрендә кала.

8 статья. **Гаризаны электрон документ рәвешендә бирү үзенчәлекләре**

Әлеге Законның 7 статьясында билгеләнгән тәртиптә «Хезмәт ветераны» исемен бирү, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү, шулай ук «Хезмәт ветераны» таныклыгын бирү турындагы гариза, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Гаризаны бирү һәм аны кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

*(2011 елның 10 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, шушы статьяның 2 өлешеннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 90 көн узгач үз көченә керә, ә әлеге статьяның 2 өлеше шушы Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәҗрибәсе мәсьәләләре буенча үз компетенциясе чикләрендә методик күрсәтмәләр чыгарырга хокуклы.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 елның 30 июне
№ 33-ТРЗ

14) инвалидларга медик-социаль экспертиза үткәрү һәм аларны реабилитацияләү;

15) дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларның актларына судтан тыш тәртиптә шикаять белдерү;

16) гадәттән тыш хәл аркасында бозылган мөлкәти хокукларын, мөлкәти булмаган шәхси хокукларын торгызу, гадәттән тыш хәл аркасында килгән зыянны түләү.

*(16 пункт 2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар мәнфәгатьләрен чагылдыралар, әгәр алар:

1) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар һәм җавап бирүчеләр булсалар:

а) күчемсез мөлкәткә алыш-бирешләрне өзү, гамәлгә яраксыз дип тану, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм алар белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу һәм мондый хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

б) торак урынына хокукны тану, социаль наем шартнамәсе, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, шул исәптән гаиләгә тәрбиягә алынган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсе буенча торак урыны бирелү, торак урынына социаль наем шартнамәсен өзү һәм туктату, торак урыныннан чыгарылу (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта), ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу;

*(2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

в) җир кишәрлегенә милекчелек хокукын, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукын, шулай ук җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын тану һәм саклап калу (бәхәсле җир кишәрлегендә яисә аның бер өлешендә гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган торак йорт яисә аның өлеше урнашкан очракта);

2) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар (мөрәҗәгать итүчеләр) булсалар:

а) алиментлар түләттерү;

4) кулланучылар хокукларын яклау (коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлешендә);

5) хезмәт шартнамәсен төзүдән эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бозарлык итеп баш тартуы, эш урынына кире кайтарылу, хезмәт хакын түләттерү, шул исәптән ихтыярсыздан эшкә чыкмаган вакыт өчен, эш бирүченең хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән мораль зыянны компенсацияләү;

6) гражданны эшсез дип тану һәм эшсезлек буенча пособие билгеләү;

7) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә яисә гадәттән тыш хәл аркасында вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

*(2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

8) социаль ярдәм чаралары бирү, аз керемле гражданнарга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү, торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләр бирү;

9) картлык буенча иминият пенсияләре, инвалидлык буенча һәм туендыручысыз калган очрак буенча пенсияләр, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек, йөклелек һәм бала тудыру, эшсезлек буенча, хезмәттә имгәнүгә яисә һөнәри авыруга бәйле пособиеләр, бала тугач бер мәртәбә бирелә торган пособие, бала карау буенча айлык пособие, мәет җирләүгә социаль пособие билгеләү, аларны яңадан исәпләү һәм түләттерү;

*(2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

10) ата (ана) булуны билгеләү һәм дәгъвалау, алиментлар түләттерү;

10[1]) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

*(10[1] пункт 2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

10[2]) ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

*(10[2] пункт 2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

11) сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнарны реабилитацияләү;

12) хокукка сәләтлелекне чикләү;

13) психиатрия ярдәме күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуларга карата шикаять белдерү;



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2004 елның 24 ноябрендә
кабул ителде

*(2004 елның 30 декабрендәге 73-ТРЗ номерлы,
2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы,
2006 елның 13 февралендәге 7-ТРЗ номерлы,
2007 елның 9 ноябрендәге 55-ТРЗ номерлы,
2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы,
2008 елның 12 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы,
2009 елның 22 декабрендәге 67-ТРЗ номерлы,
2010 елның 14 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы,
2011 елның 1 августындагы 58-ТРЗ номерлы,
2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы,
2012 елның 11 июнендәге 36-ТРЗ номерлы,
2012 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы,
2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы,
2013 елның 20 маендагы 37-ТРЗ номерлы,
2014 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы,
2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы,
2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы,
2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы,
2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы,
2015 елның 11 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы,
2015 елның 25 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы,
2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы,
2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

Әлеге Закон Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгели.

## I БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. **Әлеге Законның кулланылыш өлкәсе**

1. Әлеге Законның гамәле Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм бу Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләргә керә торган Россия Федерациясе гражданнарына кагыла.

2. Әлеге Законның гамәле, әгәр федераль закон һәм Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе белән башкача билгеләнмәгән булса, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга да кагыла.

### 2 статья. **Гражданнарның адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган категорияләре**

1. Халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә гражданнарның түбәндәге категорияләренә билгеләнә:

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга;

хезмәт ветераннарына;

реабилитацияләнгән гражданнарга;

сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган гражданнарга;

ятим балаларга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга;

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга;

уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга;

*(тугызынчы абзац 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга;

*(2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга;

*(унберенче абзац (элек унынчы) 2006 елның 13 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*



д) гадәттән тыш хәл аркасында сәламәтлегенә зыян килгән гражданнар;

е) гадәттән тыш хәл аркасында торак урыныннан мәхрүм калган йә тулысынча яисә өлешчә бүтән мөлкәтен йә документларын югалткан гражданнар;

*(8[1] пункт 2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

8[2]) реабилитацияләнгән затлар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар;

*(8[2] пункт 2016 елның 12 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

9) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукы федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә бирелгән гражданнар.

2. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарга түбәндәге очракларда телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультацияләр бирә һәм алар өчен гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзи:

1) күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләр төзү, аларны үзгәртү, өзү, гамәлгә яраксыз дип тану, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә кую (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта);

2) торак урынына хокукны тану, социаль наем шартнамәсе, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсус торак урыннарын яллау шартнамәсе буенча торак урыны бирелү, торак урынына социаль наем шартнамәсен өзү һәм туктату, торак урыныннан чыгарылу (фатир, торак йорт яисә аларның өлешләре гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган очракта), ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу;

*(2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) җир кишәрлегенә милекчелек хокукын, даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукын, шулай ук җир кишәрлеген гомерлеккә мирас итеп биләү хокукын тану һәм саклап калу (бәхәсле җир кишәрлегендә яисә аның бер өлешендә гражданның һәм аның гаиләсенең бердәнбер торак урыны булган торак йорт яисә аның бер өлеше урнашкан очракта);

$4^1$) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаиләгә урнаштыруга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затлар;

*($4^1$ пункт 2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

$4^2$) уллыкка алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, уллыкка алучылар;

*($4^2$ пункт 2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

5) стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче олы яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар;

*(2016 елның 7 маендагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләрендә тотылучы балигъ булмаганнар һәм иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче балигъ булмаганнар, шулай ук, мондый балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча (җинаятькә кагылышлы суд эшләрендә юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрдән тыш) түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

7) «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокукларының гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә түләүсез юридик ярдәмгә хокукы булган гражданнар;

8) суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган гражданнар, шулай ук, мондый гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре;

$8^1$) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнар:

а) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның һәлак булу (вафат булу) көненә аның белән теркәлгән никахта торучы ире (хатыны);

б) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның балалары;

в) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның ата-анасы;

г) гадәттән тыш хәл аркасында һәлак булган (вафат булган) затның тулаем каравында булган яисә яшәр өчен даими һәм төп керем чыганагы рәвешендә аннан ярдәм алып торган затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә аның тәрбиясендәге затлар дип танылган бүтән затлар;



хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге, онкология авырулары белән авыручы затларга;

*(уникенче абзац (элек унберенче) 2008 елның 12 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2013 елның 20 маендагы 37-ТРЗ номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга;

*(унөченче абзац (элек уникенче) 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә.

*(ундүртенче абзац (элек унөченче) 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Пенсионерларга, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә, аз керемле гражданнарга, дарулар белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

### 3 статья. **Халыкка социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау**

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең әлеге Законда билгеләнгән чараларын гамәлгә ашыру чыгымнары тапшырылган финанс чаралары күләмнәрендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла.

2. Җирле үзидарә органнары гражданнарның әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләргә хокуклы.

3. Әлеге Законның 4 – 8 статьяларында каралган айлык акчалата түләүләр күләме, инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, ел саен индексацияләнә.

4. Әлеге Законның $8^2$ статьясында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт

бирелгән органына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.

*(4 пункт 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

## II БҮЛЕК. ХАЛЫКНЫҢ АЕРЫМ КАТЕГОРИЯЛӘРЕНӘ СОЦИАЛЬ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ ЧАРАЛАРЫ

### 4 статья. **1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

ай саен 300 сум күләмендә акчалата түләү;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

түләүсез теш протезлау (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары ясау һәм ремонтлау) һәм ишетү протезлары ясау.

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

### 5 статья. **Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

1. «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән, мөрәҗәгать иткән көнгә уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 200 сум күләмендә акчалата түләү;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

торак мәйданның Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 50 про-



һәм гражданның мәнфәгатьләрен судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда чагылдыра.

### 11 статья. **Адвокатлар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Адвокатлар Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.
2. Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы эшчәнлегендә адвокатларның катнашуын оештыру Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы тарафыннан башкарыла.
3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга хезмәт өчен түләү һәм аларның мондый ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләү күләмен һәм тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

### 12 статья. **Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарның категорияләре һәм мондый ярдәмне күрсәтү очраклары**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында әлеге Законның 4 статьясында каралган барлык түләүсез юридик ярдәм төрләрен алу хокукына гражданнарның түбәндәге категорияләре ия була:

1) гаиләләренең уртача җан башына кереме Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гражданнар йә керемнәре яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган ялгыз яшәүче гражданнар (алга таба – аз керемле гражданнар);

2) I һәм II төркем инвалидлар;

3) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары;

*(2014 елның 28 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук, мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;

*(2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

**8 статья. Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнары гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруның өстәмә гарантияләрен билгеләүче муниципаль хокукый актлар чыгарырга һәм гражданнарга әлеге Законның 4 статьясында каралган барлык түләүсез юридик ярдәм төрләрен күрсәтергә хокуклы.

**9 статья. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар**

1. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар түбәндәгеләр була:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр;

2) законнар нигезендә бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары.

2. Адвокатлар Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында Федераль законда һәм әлеге Законда каралган тәртиптә катнаша.

**10 статья. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары гражданнарга түләүсез юридик ярдәмне үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма хокукый консультацияләр бирү рәвешләрендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзеп бирү рәвешендә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә



центы күләмендә субсидия. Субсидия теләсә кайсы милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия – халык өчен хезмәт күрсәтүләрнең билгеләнгән нормативлары чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүчеләргә – халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны кайтару буенча транспорт хезмәтләре хакыннан. Субсидия торак фонд төренә бәйсез рәвештә бирелә;

чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлау (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясе чыгымнарыннан гайре, теш протезлары ясау һәм ремонтлау) һәм ишетү протезлары ясау.

*(алтынчы абзац 2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2. Әлеге статьяның 1 пунктында каралганнан үзгә нигезләр буенча пенсияләр алучы йә эше (хезмәте) өчен гомер буе акча алучы хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтүгә хокук әлеге статья нигезендә, әгәр мөрәҗәгать иткән көнгә аларның уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаса, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң бирелә.

*(2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

**$5^1$ статья. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

1. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» Татарстан Республикасы орденына лаек булган һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажга ия булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә

дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

*(2014 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

торак мәйданының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә субсидия. Субсидия барлык милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

халык өчен – хезмәт күрсәтүләрдән файдалану буенча билгеләнгән нормативлар чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүчеләргә, халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны илтеп җиткерү буенча транспорт хезмәтләре хакыннан чыгып, коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә субсидия. Субсидия торак фондның төренә бәйсез рәвештә бирелә;

чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә субсидия;

*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 200 сум күләмендә акчалата түләү;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлары ясату (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары әзерләү һәм ремонтлау) һәм колак аппаратлары ясату.

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2. «Фидакарь хезмәт өчен» Татарстан Республикасы медаленә лаек булган һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажга ия булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

*(2014 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 25 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

торак мәйданының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия барлык милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

халык өчен – хезмәт күрсәтүләрдән файдалану буенча билгеләнгән нормативлар чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортлар-



1) Татарстан Республикасында гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алуын законнар белән җайга салу;

2) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр башкару.

7 статья. **Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасының эшләвен, үсүен һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасына ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

2) гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) һәм аның компетенциясен билгеләү;

3) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасына керүче Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын, алар ведомствосындагы учреждениеләрне һәм бүтән оешмаларны билгеләү, аларның компетенциясен билгеләү;

4) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга һәм бүтән субъектларга хезмәт өчен түләү һәм аларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә тотылган чыгымнарын компенсацияләү күләмен һәм тәртибен билгеләү;

5) гражданнарның түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан кирәкле бюджет ассигнованиеләре күләмен билгеләү, шулай ук Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә шушы чыгымнарны финанслауны тәэмин итү;

$5^1$) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнарның дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү тәртибен һәм шартларын раслау;

*($5^1$ пункт 2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

6) гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасының эшләве, үсүе һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасына ярдәм күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне башкару.

**3 статья. Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә бәйле мөнәсәбәтләр Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән җайга салына.

**4 статья. Түләүсез юридик ярдәм төрләре**

1. Түләүсез юридик ярдәм түбәндәге төрләрдә күрсәтелә:

1) телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультацияләр бирү;

2) гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү;

3) федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнарның мәнфәгатьләрен чагылдыру.

2. Түләүсез юридик ярдәм законнар белән тыелмаган бүтән төрләрдә дә күрсәтелергә мөмкин.

**5 статья. Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләрен билгеләү;

2) дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның Татарстан Республикасы территориясендә үзара хезмәттәшлеге тәртибен федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында билгеләү;

3) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр башкару.

**6 статья. Гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:



да яшәүчеләргә, халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны илтеп җиткерү буенча транспорт хезмәтләре хакыннан чыгып, коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия торак фондның төренә бәйсез рәвештә бирелә;

чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә субсидия;

*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 200 сум күләмендә акчалата түләү;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлары ясату (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары әзерләү һәм ремонтлау) һәм колак аппаратлары ясату.

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

3. Татарстан Республикасының әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында саналмаган дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләнүгә кирәкле стажга ия булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

*(2014 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

торак мәйданының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия барлык милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

халык өчен – хезмәт күрсәтүләрдән файдалану буенча билгеләнгән нормативлар чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүчеләргә, халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны илтеп җиткерү буенча транспорт хезмәтләре хакыннан чыгып, коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия торак фондның төренә бәйсез рәвештә бирелә;

чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия;

*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 200 сум күләмендә акчалата түләү;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлары ясату (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары әзерләү һәм ремонтлау) һәм колак аппаратлары ясату.

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

4. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажга ия булган, пенсияләрен башка нигезләр буенча алучы йә эш (хезмәт) өчен гомерлек акчалата түләү алучы затларга әлеге статья буенча социаль ярдәм күрсәтелү хокукы «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә пенсия хокукы бирелә торган яшькә җиткәннән соң бирелә.

*(2014 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

*(статья 2006 елның 13 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

6 статья. **Реабилитацияләнгән гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында**

Реабилитацияләнгән гражданнарга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

*(2012 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 300 сум күләмендә акчалата түләү;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

телефон куюга бәйле чыгымнарны каплау;

торак мәйданның Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия теләсә кайсы милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия — халык өчен хезмәт күрсәтүләрнең билгеләнгән нормативлары чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүчеләргә — халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны кайтару буенча транспорт



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 11 октябрендә
кабул ителде

*(2013 елның 11 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы,
2014 елның 28 февралендәге 12-ТРЗ номерлы,
2014 елның 15 декабрендәге 117-ТРЗ номерлы,
2016 елның 7 маендагы 33-ТРЗ номерлы,
2016 елның 12 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы
Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

1 статья. **Әлеге Законның хокукый җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба — Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба — гражданнар) квалификацияле түләүсез юридик ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы территориясендә тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законның максатлары**

Әлеге Законның максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданнарның федераль законнарда һәм әлеге Законда каралган очракларда түләүсез күрсәтелә торган квалификацияле юридик ярдәм (алга таба — түләүсез юридик ярдәм) алу хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырудан;

2) Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасын булдырудан һәм үстерүдән, дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасын үстерүгә булышлык итүдән һәм аңа дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтүдән;

3) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру, аларның законлы мәнфәгатьләрен яклау, социаль якланыш дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудырудан, шулай ук аларның гадел хөкемгә ирешүен тәэмин итүдән.

яисә бүтән норматив хокукый акт буенча айлык акчалата бер түләү бирелә.

*(өченче абзац 2011 елның 1 августындагы 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

## III БҮЛЕК. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

### 10 статья. **Халыкка адреслы социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән баш тартуга шикаять бирү**

Халыкка адреслы социаль ярдәмнең әлеге Законда билгеләнгән чараларын күрсәтүдән баш тартуга карата шикаять социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле югары органга һәм (яки) судка бирелергә мөмкин.

### 11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2005 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән 10 көннән дә иртәрәк түгел, үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 12 статьясы рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

### 12 статья. **Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын туры китерү**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2005 елның 1 гыйнварына кадәр үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

### 13 статья. **Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

«1941 – 1945 елларда Германияне җиңгән өчен» медале яисә «Японияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы гражданнарының өстәмә ташламалары һәм социаль гарантияләре турында» 1994 елның 20 июлендәге 2192-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«1941 – 1945 елларда Германияне җиңгән өчен» медале яисә «Японияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы гражданнарының өстәмә ташламалары һәм социаль гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» 2002 елның 24 июнендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль
2004 елның 8 декабре
№ 63-ТРЗ

хезмәтләре хакыннан. Субсидия торак фонды төренә бәйсез рәвештә бирелә;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлары ясату (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары әзерләү һәм ремонтлау) һәм колак аппаратлары ясату;

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

кумүгә социаль пособие түләү чыгымнарын исәпләмичә, күмү чыгымнарын каплау.

### 7 статья. **Сәяси репрессияләрдә зыян күргән гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

Сәяси репрессияләрдә зыян күргән гражданнарга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

*(2012 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

ай саен 250 сум күләмендә акчалата түләү;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

торак мәйданның Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия. Субсидия теләсә кайсы милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затка бирелә;

коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия – халык өчен хезмәт күрсәтүләрнең билгеләнгән нормативлары чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүчеләргә – халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык һәм бу ягулыкны кайтару буенча транспорт хезмәтләре хакыннан. Субсидия торак фонды төренә бәйсез рәвештә бирелә;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң түләүсез теш протезлары ясату (кыйммәтле металлар һәм металлокерамика бәясен түләү чыгымнарыннан гайре, теш протезлары әзерләү һәм ремонтлау) һәм колак аппаратлары ясату.

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 125-ТРЗ номерлы, 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

8 статья. **Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга һәм балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары**

*(исеме 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1. Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, уллыкка бала алган гаилә кайгыртуына (попечительлегенә) тапшырылган балаларга айлык мәктәпкәчә яштәге балалар өчен – 1800 сум, мәктәп укучылары өчен – 2300 сум күләмендә акчалата түләү бирелә.

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Төп уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмдә һәм тәртиптә транспортта йөргән өчен субсидия бирелә.

*(2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2[1]. Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга түбәндәгеләр бирелә:

югары белем бирү мәгариф оешмаларының әзерлек бүлекләрендә түләүсез уку;

көндезге уку рәвешендә квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасы буенча икенче урта һөнәри белемне түләүсез алу;

квалификацияле эшчеләр әзерләү программасы буенча түләүсез беренче һәм икенче урта һөнәри белем алу;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә бер мәртәбә белем алу.

Урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын, урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын үзләштерү кысаларында һөнәри белем алган ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә бер мәртәбә белем алу хокукы саклана.

*(2[1] пункт 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән укып һәм тәрбияләнеп, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган



*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән инвалидларның һәм инвалид балаларның «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясындагы алтынчы өлешендә каралган өстәмә торак мәйданына хокукы булганда, торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) мондый хокукны исәпкә алып бирелә.

3. Торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе һәм аны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

*(2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*(статья 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

9 статья. **Халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү**

1. Әлеге Законның 4 – 8[2] статьяларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

*(2008 елның 12 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы, 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

2. Әлеге Законның 4 – 7 статьяларында билгеләнгән берничә нигез буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларын берьюлы алу хокукына ия булган гражданга, социаль ярдәм чаралары гражданның теләге белән аларның берсе буенча күрсәтелә.

Бер үк вакытта әлеге Законның 4 – 7 статьялары һәм федераль законнар нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган гражданнарга, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәсә, нигезләрнең берсе буенча гражданнар сайлаган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

*(икенче абзац 2004 елның 30 декабрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

Әгәр граждан бер үк вакытта әлеге Закон һәм федераль закон яисә бүтән норматив хокукый акт буенча айлык акчалата түләүгә аны билгеләү нигезенә бәйсез рәвештә («Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә), «Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә айлык акчалата түләү билгеләү очракларыннан гайре) хокуклы булса, гражданга, ул сайлап алганча, йә әлеге Закон, йә федераль закон

малар чикләрендә сатып алына торган ягулык бәясеннән. Субсидия торак фонды төренә бәйсез рәвештә бирелә;

гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга транспортта йөрүгә аена 120 сум күләмендә айлык субсидия – алар укып бетергәнче, әмма унсигез яшькә җиткәннән соң түгел.

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

8[1] статья. **Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге, онкология авырулары белән авыручы затларга социаль ярдәм чаралары**

1. Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.

2. Онкология авырулары белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтә торган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларындагы дәвалану урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.

*(2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

*(статья 2008 елның 12 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде, 2013 елның 20 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

8[2] статья. **Авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга һәм авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм чаралары**

1. Билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.



балалар өчен оешмаларны, ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрен тәмамлаучылар, Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә укып белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучылар – ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар, Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә укуын дәвам итүче затлардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмдә һәм тәртиптә түләүсез кием-салым, аяк киеме комплекты, йомшак инвентарь, җиһазлар һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата пособие белән тәэмин ителәләр.

Әгәр социаль ярдәмнең өстәмә гарантияләре ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга алар элек белем алган һәм (яисә) тәрбияләнгән оешма акчалары исәбеннән бирелгән булса, аларга әлеге пунктта каралган гарантияләр бирелми.

*(2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

4. Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга тулы дәүләт тәэминаты белән беррәттән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

айлык стипендия бирелә, аның күләме әлеге мәгариф оешмасында белем алучылар өчен билгеләнгән стипендия күләме белән чагыштырганда кимендә илле процентка арттырыла;

өч айлык дәүләт социаль стипендиясе күләмендә уку әдәбияты һәм язма әсбаплар сатып алуга еллык пособие бирелә.

*(2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

5. Социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булмаган

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урыннарын яллаучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр аларның элек били торган торак урыннарында яшәүләре мөмкин түгел дип танылса, махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителергә тиеш.

Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга мөлкәткә һәм торак урынына хокукларның өстәмә гарантияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

*(2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

6. 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган авырулар исемлегенә кертелгән авыру булганда – түләүсез;

*(2009 елның 22 декабрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

гомерләренең беренче өч елында балаларны дарулар белән түләүсез тәэмин итү, аларның исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә;

*дүртенче абзац үз көчен югалткан;*

*(2008 елның 20 маендагы 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

лагерьларда, шифаханәләрдә, шифаханә-профилакторийларда балаларны савыктыруга юлламалар бирү;

*(2010 елның 14 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларны уку чорында бер укучыга көненә 3 сум күләмендә туклану белән тәэмин итү.

*(2010 елның 14 октябрендәге 68-ТРЗ, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

7. Әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә рәвештә, җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган балалы гаиләләр өчен социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:



16 яшькә кадәрге балага айлык пособие (гомуми белем бирү оешмасында белем алучыга – укып бетергәнче, әмма 18 яшькә җиткәннән соң түгел):

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

164 сум;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2007 елның 9 ноябрендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

ялгыз ананың баласына – 438 сум;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2006 елның 13 февралендәге 7-ТРЗ номерлы, 2007 елның 9 ноябрендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

ата-аналары алиментлар түләүдән баш тарткан очракта яки Россия Федерациясе законнары белән каралган башка очракларда алиментлар түләттереп булмаса, балага; сержант, старшина, солдат һәм матрос сыйфатында хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына, шулай ук хәрби хезмәтне үтәү турында контракт төзегәнче атасы хәрби һөнәри белем бирү оешмасында һәм югары белем хәрби белем бирү оешмасында белем алган балага – 246 сум;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы, 2007 елның 9 ноябрендәге 55-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)*

өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү.

*(алтынчы абзац 2009 елның 22 декабрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

8. Әлеге статьяның 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән социаль ярдәм чараларына өстәмә рәвештә, уллыкка алган балаларны да кертеп, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

6 яшькә кадәрге бала өчен дарулар сатып алуга аена 50 сум күләмендә субсидия;

*(2005 елның 3 февралендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

торак мәйданның Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торакка түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия. Субсидия теләсә кайсы милек рәвешендәге торак фондта яшәүче затларга бирелә;

коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 30 проценты күләмендә субсидия – халык өчен билгеләнгән хезмәт күрсәтүләрнең билгеләнгән нормативлары чикләрендә, ә үзәктән җылытылмый торган йортларда яшәүче гаиләләр өчен – халыкка сату өчен билгеләнгән нор-